Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге
Сәләнгеш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«19» ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2022 елның 22 ноябрендә түбәндәге сораулар белән узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1. 2023 елда үзара салым акчаларын кертү һәм тоту турында гражданнар каравына чыгарыла торган мәсьәлә текстына үзгәрешләр кертү турында;
2. 2023 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында..

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 308 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 177 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

1. Беренче мәсьәлә: 2023 елда үзара салым акчаларын кертү һәм тоту турында гражданнар каравына чыгарыла торган мәсьәлә текстына үзгәрешләр кертү турында. 2023 елда үзара салым кертү турында гражданнар җыенында каралуга чыгарылган мәсьәләгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2023 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сәләнгеш авылында су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм төзекләндерү;
- Сәләнгеш авылы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту»

сүзләрен «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2023 елда 1200 (бер мең ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сәләнгеш авылында су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм төзекләндерү;
- Сәләнгеш авылы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- Сәләнгеш авылы территориясен төзекләндерү» сүзләренә алыштырырга:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 163 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен 14 кеше тавыш бирде.

2. Икенче сорау буенча: Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2023 елда 1200 (бер мең ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне

башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Сәләнгеш авылында су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм төзекләндерү;
- Сәләнгеш авылы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- Сәләнгеш авылы территориясен төзекләндерү».
«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 163 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен 14 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәләләр буенча кабул ителгән карарларны танырга:

- 2023 елда үзара салым акчаларын кертү һәм тоту турында гражданнар каравына чыгарыла торган мәсьәлә текстына үзгәрешләр кертү турында;
- 2023 елда үзара салым акчаларын кертү һәм тоту турында.

3. Халык җыенының нәтиҗәләрен «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авылының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыены рәисе: А.Н. Пинин

Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы: А.Н. Пинин